МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

11.01.2024 Казан № 7-р

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә газ бүлү челтәрләре объектларының саклык зонасын урнаштыру турында

Россия Федерациясе Җир Кодексының 56, 106 статьяларына, «Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы № 69-ФЗ Федераль законга, “Күчемсез милекнең дәүләт теркәве турында” 2015 елның 13 июлендәге № 218-ФЗ Федераль законның 32 статьясына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләренә туры китереп, «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ мөрәҗәгате нигезендә, «Татарстан Республикасы пространство мәгълүматы фонды» ДБУның (29.12.2023 № 04А-04/3443) хатын искә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.08.2007 ел, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмәсенә таянып, Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы карар чыгарды:

1. Газ бүлү челтәрләре объектларының саклык зонасын (ТР Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара ав.дагы Насыйри, И Шакиров ур. торак йортлар (Түбән басымлы Р < 0,003 МПа газүткәргеч); ТР Кукмара МБ Манзарас ав.да газүткәргеч һәм суүткәргеч челтәре төзелеше. Газ белән тәэмин итү. Урта басымлы Р < 0,3 Мпа газүткәргеч; Кукмара районының Кукмара б.дә Мирсәй

Әмир ур.даны 6 йортка түбән басымлы бүлгеч газүткәргеч; ТР Кукмара МБ Манзарас ав.да көньяк өлешендә мәйданны торак йортлар өчен комплекслы әзерләү. Түбән басымлы тышкы газүткәргеч; ТР Кукмара МБ Манзарас ав.да көньяк өлешендә мәйданны торак йортлар өчен комплекслы әзерләү (төзелешнең икенче чираты). Түбән басымлы газүткәргеч) 9 832,98 м озынлыкта, гомуми мәйданы (37266 ± 68) кв.м территориядә, территорияне файдалануның аерым шартлары булган зона чикләре урнашкан урынның текстлы һәм график тасвирламасындагы мәгълүматка, газ бүлү челтәре чикләренең характерлы нокталарының координаталары исемлегенә туры китереп урнаштырырга (бастырып чыгару каралмаган).

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән газ бүлү челтәрләре объектының саклау зоналары чикләренә тулысынча яки өлешчә туры килгән җир кишәрлекләренә газ бүлү челтәрен эксплуатацияләү срогына Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган газ бүлү челтәрен саклау кагыйдәләрендә каралган чикләүләр (йөкләүләр) кертергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары А.А.Кыямовка йөкләргә.

**Министр** **Ф.Ә.Әһлиуллин**